Республика Татарстан
СОВЕТ
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

“12” нче ноябрь 2020 ел № 10

Ләке авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 22 нче февралендә кабул иткән 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ләке авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Ләке авыл жирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 22 нче февралендә кабул иткән 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым аванс белән, узган хисап чорыннан агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процентының тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.«Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылган көннән бер айдан да иртәрәк түгел».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ләке авыл җирлеге
Советы Рәисе Л. И. Шәрипова